КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июль г.Казань № 799

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы һәм «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгының «Мәгариф системасында инновация инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 22 мартындагы 21н номерлы боерыгы белән расланган Мәгариф системасында инновация инфраструктурасын булдыру һәм аның эшләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 сентябрь, 640 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 сентябрь, 640 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 20 октябрь, 798 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 сентябрь, 640 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 10 март, 144 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 июль, 799 нчы
карары белән расланды

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм
мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның
берләшмәләрен төбәк инновация мәйданчыклары дип тану
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 4 өлеше, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлеше, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгының «Мәгариф системасында инновация инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 22 мартындагы 21н номерлы боерыгы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче башка оешмаларны, шулай ук аларның берләшмәләрен (алга таба – оешмалар) төбәк инновация мәйданчыклары дип тануны оештыру процедурасын билгели.

2. Төбәк инновация мәйданчыклары эшчәнлегенең төп юнәлешләре:

а) түбәндәгеләрне эшләү, апробацияләү һәм (яки) кулланышка кертү:

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда белем бирү эчтәлегенең һәм тәрбия бирү системаларының яңа элементларын, яңа педагогик технологияләрне, укыту-методик һәм укыту-лаборатория комплексларын, укытуның һәм тәрбияләүнең формаларын, ысулларын һәм чараларын, шул исәптән дәүләткә карамаган сектор ресурсларыннан файдаланып;

катлаулы социаль шартларда эшләүче мәгариф оешмаларының федераль төп белем бирү программаларын, инновацион белем бирү программаларын, үсеш программаларын;

һөнәри белем бирү өлкәсендә Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләре нигезендә кадрлар һәм фәнни потенциалны формалаштыруны тәэмин итә торган яңа әзерлек профильләрен (белгечлекләрен);

заманча мәгариф технологияләрен куллану нигезендә кадрлар, шул исәптән педагогик, фәнни һәм фәнни-педагогик хезмәткәрләрен һәм мәгариф өлкәсенең җитәкче хезмәткәрләрен әзерләү, һөнәри яңадан әзерләү һәм (яки) аларның квалификациясен күтәрү методикаларын;

төрле дәрәҗәләрдә, шул исәптән заманча технологияләрне кулланып, мәгариф белән идарә итүнең яңа механизмнарын, формаларын һәм ысулларын;

мәгариф белән идарә итүдә җәмәгатьчелек катнашуындагы яңа институтларны;

мәгариф оешмалары берләшмәләренең һәм мәгариф өлкәсе хезмәткәрләренең эшчәнлеген үзе җайга сала торган яңа механизмнарны, шулай ук мәгариф оешмаларының челтәрле хезмәттәшлеген;

б) мәгариф өлкәсендә мәгариф системасын укыту-методик, оештыру, хокукый, финанс-икътисадый, кадрлар, матди-техник тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән башка инновация эшчәнлеге.

3. Төбәк инновация мәйданчыклары мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инновация проектлары (программалары) кысаларында да, үзләре тарафыннан эшләнгән инновация проектлары (программалары) кысаларында да бер яисә берничә юнәлеш буенча эшчәнлек алып бара.

4. Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, мәгариф системасын модернизацияләүне һәм үстерүне тәэмин итү, дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру өчен әһәмиятле булган инновация проектларын (программаларын) гамәлгә ашыручы теләсә нинди оештыру-хокук формасындагы, типтагы, ведомство карамагындагы (алар булганда) оешмалар төбәк инновация мәйданчыклары дип таныла.

## II. Төбәк инновация мәйданчыкларының эшчәнлеге белән идарә итү

5. Мәгариф өлкәсендә инновация эшчәнлеген координацияләү һәм үстерү максатларында Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә инновация инфраструктурасын үстерү мәсьәләләре буенча координация советы (алга таба – координация советы) төзелә.

Координация советының составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Координация советына Министрлык вәкилләре, шулай ук килешү буенча Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, фәнни оешмалар, мәгариф өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә.

Координация советын рәис җитәкли.

Координация советы составына координация советы рәисе урынбасары, координация советы әгъзалары, секретарь керә.

Координация советы үз эшчәнлеген Министрлык боерыгы белән раслана торган регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

6. Координация советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

төбәк инновация мәйданчыклары эшчәнлегенең төп юнәлешләрен һәм аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге критерийларын формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

инновация процессларына экспертиза үткәрүне оештыру һәм анализлау, мәгариф системасын үстерүне тәэмин итә торган механизмнарны ачыклау;

массакүләм белем бирү практикасында төбәк инновация мәйданчыклары эшчәнлеге нәтиҗәләрен файдалану буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Министрлыкның оешмаларны төбәк инновация мәйданчыклары дип тану турындагы тәкъдимнәрен әзерләү;

Министрлыкның рәсми соравы буенча мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре нигезендә мәгарифне үстерү һәм модернизацияләү белән идарә итү нәтиҗәлелеге турында аналитик материаллар әзерләү.

7. Координация советы эшчәнлегенең төп формасы – кирәк булуга карап, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр үткәрелә торган утырышлар.

Координация советы утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

8. Координация советы карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Координация советы карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга координация советының утырышта катнашкан һәр әгъзасы тарафыннан кул куела. Беркетмәләрдә координация советы әгъзаларының аерым фикере (ул булса) күрсәтелә.

Координация советы әгъзаларының тавышлары тигез булганда, координация советы рәисенең, ә рәис булмаганда – утырышта рәис булучы урынбасарның тавышы хәлиткеч була.

## III. Оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип тану тәртибе

9. Оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип тану Министрлык тарафыннан координация советы тәкъдимнәре нигезендә, төбәк инновация мәйданчыклары исемлеген раслау турында боерык кабул итү юлы белән башкарыла.

Оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип тану инновация проектын (программаларын) тормышка ашыру чорында гамәлгә ашырыла.

10. Оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип тану өчен оешма тарафыннан, агымдагы елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча, координация советына Министрлык раслаган форма буенча кәгазьдә гариза тапшырыла, анда түбәндәгеләр бирелергә тиеш:

оешманың исеме һәм урнашу урыны, элемтәгә керү өчен телефоннары;

тәкъдим ителә торган инновация проектының (программасының) максатлары, бурычлары һәм төп идеясе (идеяләре), мәгариф системасын үстерү өчен аның әһәмиятен нигезләү;

мәгариф турындагы законнар нигезендә инновация проектын (программасын) яки инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый акт проекты эчтәлеге буенча тәкъдимнәрне тормышка ашыру мөмкинлеген нигезләү;

инновация проекты (программасы) нәтиҗәләрен тарату һәм массакүләм белем бирү тәҗрибәсенә кертү буенча тәкъдимнәр;

инновация проекты (программасы) гамәлгә ашырылып беткәннән соң аның нәтиҗәләренең (аның ресурслар белән тәэмин ителеше механизмнарын кертеп) тотрыклылыгын нигезләү.

Заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

оешма идарәсендәге вәкаләтле органның инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыруда катнашу турында карары;

инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру программасы: башлангыч теоретик нигезләмәләр, эшчәнлек этаплары, эчтәлеге һәм ысуллары, һәр этап буенча фаразлана торган нәтиҗәләр, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре, эшләрне оештыру өчен кирәкле шартлар, нәтиҗәләрнең дөреслеген контрольдә тоту һәм

тәэмин итү чаралары, инновация проекты (программасы) юнәлеше буенча фәнни һәм (яки) укыту-методик эшләнмәләр исемлеге;

этаплар буенча инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру срокларын һәм соңгы нәтиҗәләрнең исемлеген күрсәтеп, календарь план.

11. Координация советына кергән заявкалар экспертизага җибәрелә.

12. Заявкаларга экспертиза ясау максатларында Министрлык тарафыннан эксперт советы төзелә, аның составы Министрлык боерыгы белән раслана. Эксперт советы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, фәнни оешмалар һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән төзелә, аның составында кимендә биш әгъза (совет рәисен, рәис урынбасарын, әгъзаларын һәм секретарьне кертеп) була.

13. Эксперт советы түбәндәгеләрне башкара:

заявкалар бирелгән көннән 30 календарь көн эчендә аларга экспертиза ясауны;

экспертиза ясау тәмамланган көннән биш календарь көн эчендә координация советына заявкаларга экспертиза ясау нәтиҗәләре турында бәяләмәләр бирүне.

Эксперт советының эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Әгәр утырышта эксперт советы әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

Заявкаларга экспертиза ясау – аларның әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү. Эксперт советы карары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы, ә ул булмаганда рәис урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

Эксперт советы карары бәяләмә формасында рәсмиләштерелә, аңа рәиснең яисә рәис булмаганда рәис урынбасарының һәм секретарьнең имзасы куела.

14. Координация советы экспертлар советы тарафыннан тәкъдим ителгән бәяләмәләрне карап тикшерә һәм, агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип тану турында тәкъдим кертә.

15. Оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип танудан баш тарту өчен нигез:

заявканың әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявканың мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенең актуаль юнәлешләренә туры килмәве;

заявкада инновация эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, ысуллары, чаралары белән көтелә торган нәтиҗәләренең туры килмәве.

Әлеге пунктта билгеләнгән баш тарту нигезләрен күрсәтеп, оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип танудан баш тарту турында хәбәрнамә Министрлык тарафыннан оешмага Министрлыкның төбәк инновация мәйданчыклары исемлеген раслау турындагы боерыгы чыккан датадан биш эш көне эчендә җибәрелә.

Төбәк инновация мәйданчыгы дип тануга кабат заявка тапшыру, әлеге Тәртипнең 10 пунктындагы беренче абзацында билгеләнгән срокны исәпкә алып, оешманы төбәк инновация мәйданчыгы дип танудан баш тарту турында карар кабул ителгән заявка оешма тарафыннан агымдагы елда бирелгән көннән бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

16. Инновация инфраструктурасына керә торган төбәк инновация мәйданчыклары исемлеге, координация советыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә һәм эксперт

советының бәяләмәсен исәпкә алып, координация советы тәкъдимнәре кергән көннән биш календарь көн эчендә Министрлык боерыгы белән раслана, аңа эксперт советының бәяләмәсе теркәлә.

Министрлыкның төбәк инновация мәйданчыклары исемлеген раслау турындагы боерыгы Министрлыкның сайтында әлеге боерык чыккан көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә урнаштырыла.

17. Инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру срогы чыкканнан соң, Министрлык координация советының тәкъдиме буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

төбәк инновация мәйданчыгы эшчәнлеген туктату турында;

төбәк инновация мәйданчыгы эшчәнлеген озайту турында.

18. Төбәк инновация мәйданчыгы эшчәнлеге түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыруны дәвам итү мөмкин булмавын яки максатка ярашсызлыгын раслый торган арадаш нәтиҗәләр алынганда;

инновация проектында (программасында) бәян ителгән төбәк инновация мәйданчыгы тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләр тиешенчә үтәлмәгәндә;

төбәк инновация мәйданчыгы дип танылган оешма тарафыннан инновация проектын (программасын) гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнары бозылганда;

инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру турында ел саен бирелә торган хисап тапшырылмаганда яки үз вакытында тапшырылмаганда.

## IV. Төбәк инновация мәйданчыкларының эшчәнлеге

19. Төбәк инновация мәйданчыклары үз эшчәнлеген заявкага теркәлгән инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру программасы нигезендә гамәлгә ашыра.

20. Төбәк инновация мәйданчыкларының эшчәнлеге Министрлык тарафыннан инновация эшчәнлегенең һәр юнәлеше буенча билгеләнгән төбәк операторы тарафыннан координацияләнә.

Төбәк операторы түбәндәгеләрне башкара:

төбәк инновация мәйданчыкларының эшчәнлеген оештыру-аналитик, фәнни-методик яктан тәэмин итү һәм консультация ярдәме күрсәтүне;

инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру турында ел саен бирелә торган хисапларга экспертиза ясауны;

алынган инновация проекты (программасы) нәтиҗәләренең әһәмияте һәм аларны массакүләм белем бирү практикасында файдалану мөмкин булган ысуллар турында бәяләмәләр төзүне;

координация советына төбәк инновация мәйданчыгы эшчәнлеген туктату (шул исәптән вакытыннан алда) кирәклеге турында яки озайту турында бәяләмә кертүне.

21. Инновация проекты (программасы) кысаларында төбәк инновация мәйданчыклары:

үз эшчәнлеген, кирәк булганда фәнни консультантлар җәлеп итеп, планлаштыра;

гамәлгә ашырыла торган инновация проектын (программасын) мониторинглауны гамәлгә ашыра;

балигъ булмаган укучыларның һәм башка кызыксынучы затларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыруның максатлары, бурычлары, механизмнары, гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат биреп, инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыруда үз вакытында һәм дөрес мәгълүмат биреп ярдәм күрсәтүне оештыра.

22. Төбәк инновация мәйданчыклары:

расланган инновация проектын (программасын) билгеләнгән срокларда гамәлгә ашыра;

белем бирү барышында катнашучыларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен тәэмин итә;

барлыкка килгән, инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыруга комачаулый торган, инновация проектын (программасын) яки эшләрнең календарь планын үтәмәүгә китерергә мөмкин булган мәсьәләләр турында Министрлыкка үз вакытында хәбәр итә.

23. Төбәк инновация мәйданчыклары ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 10 сентябренә кадәр, инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру турында язма хисапларны төбәк операторына экспертизага кертә. Экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча төбәк операторы төбәк инновация мәйданчыгының хисабын алган датадан календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә алынган инновация проекты (программасы) нәтиҗәләренең әһәмияте һәм аларны массакүләм белем бирү практикасында файдалану мөмкин булган ысуллар турындагы бәяләмәләрне координация советына кертә.

24. Төбәк инновация мәйданчыклары хисап чорыннан соң килә торган елның 10 октябренә кадәр үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында инновация проектын (программасын) гамәлгә ашыру турында ел саен бирелә торган хисап урнаштыра.